


Кәлимуллин Гәлиәхмәтнең фронттан килгән хатлары

**Сагынычлы сәлам хатым.**

Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле булып торучы әти һәм әни. Мин сезгә үземнең йөрәгемнән кайнап чыккан ялкынлы сәламнәремне сезгә озатып каламын. Һәм дә Мәдинә белән Әминәгә миннән бик күп сәламнәремне озатып калам. Һәм дә Нуриәхмәт белән Мехәмәтнурга миннән бик күп сәламнәремне озатып калам. Һәм дә Сәетнур белән Диләфрүз җаныма миннән яшьбуыннарча бик күп сәламнәремне озатып калам. Һәм дә мине белүче дусларыма барчасына да бик күп сәламнәремне озатып каламын. Мин сәламнәремне шушында тәмамлыйм. Хәзер үземнең һәм сезнең тормыш якларыгызга тукталмакчы буламын. Мин сезнең 20 – февральдә язган хатыгызны 4-мартта алып укыдым, хатыгызданиләр язган бар да мәгълүм булды, хатны алып уку белән үзегезне күреп сөйләшкәндәй булдым. Мин үзем бер көе генә армия сафында хезмәтемне итеп ятам, тамаклар тук, өсләр бөтен, минем өчен кайгырмагыз әти һәм әни, минем өчен бик борчылма әти һәм әни, исән булсам, үлмәсәк, авылга кайтырга тырышырбыз инде, авылда байтак кешеләрнең исәнлекләрен белдем, ну ләкин мин дә бик борчыламын. Безнең монда эшләр беркөе, әмма вә ләкин озакламый яңадан да тегендә барырга хәзерләнәбез, шушы көннәрдә китәбез, белмим инде нинди хәлләр булыр, исән булсак кайтырбыз. Сез миңа башка хат язмагыз, без моннан китәбез, Бу хатым актык хатым булыр инде, моңылчы тыныч яшәгән идек, моннан соң белмим инде ничек булыр, менә шулай әти әни минем хәлләр, башка миңа хат язмагыз бу адрес белән, вактым булса фронтта адрес бирсәләр язармын хат, әгәр дә билгеле булмаса яза алмам, гаепләмәгез, кайта алмабыздыр, ахры, сезне күреп булмастыр инде, белмим тагы бәхет эшен белеп булмый, без әле тиз җибәрерләр дип йөрмәгән идек, бүген болай, ә иртәгә тегеләй димәсәң, көннән-көн яңа эш. Шулай, туганнар, кайтуларым икеле тора, әти-әни, үзегезне бетермәгез, бер мин генә түгел, бөтен ил белән ничек тә үләргә тырышмассың тырышуын, немецләрне бетереп өйгә кайтырга дип безгә теләп ятыгыз. Немец гаскәрен бетереп өйгә кайтырга язсын иде инде. Белеп булмый инде. Рәхәт яшәп булмастыр, ахры, килде безнең яшүсмер вакытка.

Бөтен кышны калтырап уздырдык бернинди рәхәтлек күрмәдек, булды төрле көннәребез. Шушы көннәрдә китәбез, башка хат көтмәгез. Әгәр дә арам, вакытыбыз булса, адрес билгеле булса, хатка йөдәтмәмен бу хатым актыгы хатым булыр. Җибәрә алмадым сезгә карточкамны, төшә дә алмадым, йөрдем төшәмен дип, шәһәргә дә чыгармадылар. Хатка язып сүз бетми, кайтып кереп өйләрдә сөйләшергә язсын, ул вакытта барлык күргәннәрне сөйләр идек, безнең бәхетләр булмады инде. Ярый, сүзем бетте, исәнлекне теләп калучы улыгыз Галиәхмәттән сезгә рәхәт тормыш теләп калам. Яздым 9-март көнне. Нуриәхмәт, хатыңны укыдым, бик сөендем. Тагы юлда хат язармын әле.

Ярый исән булыгыз. Ачуланмагыз бу хатыма бик ашыгып кына яздым, - кайгырмагыз.

Исән булсам кайтырмын әле

Язучы (имза)(имза)(имза)(имза)(имза)(имза)

9 март 42 ел

Г. Казань Бондюжский р-н деревне Бизяки передать: Калимуллину Мифтаху из г. Ульяновск пІя 120І9 (на оттиске штампа 120 – прим. Х.Р.)

Письмо на почту поступило 20.3.42

**Сагынычлы сәлам хатымны язам. 25. 2.42 ел**

Исәнмесез бу дөнъяда иң якын күргән сеңлем, мин сиңа үземнең йөрәгемнәнкайнап чыккан ялкынлы сәламнәремне шушы начар гына кулъязмам аша, без ки Ульяновски шәһәрендә хезмәт итүче абыеңнан армееөлар санынча мин сиңа чын теләгемнән чыгып бер күрергә зар булган сәламнәремне язып калам. Һәм дә мине белүче дусларыма, ягъни Мәүлиха белән Фәрхенурга миннән комсомолларча ялкынлы сәлам. Һәм дә Әминә белән Саниягә миннән бик күп сәлам. Һәм дә Гыйлмиса белән Мәрдиягә миннән комсомолларча кайнар сәламнәремне озатып калам. Һәм Ідә (бу урында ертып алынган – Х.Р.) Нуриәхмәткә миннән яшьбуыннарча сәламнәремне озатып калам. Һәм дә мине белүче барлык дусларыма, мине сораучыларга барчасына да миннән сәлам. Мин сәламнәремне шушының белән тәмамлыйм, хәзер үземнең һәм синең хәлләреңә тукталмакчы булам. Мин сеңлем Мәдинә бүгенге көндә Ульяновски шәһәрендә хезмәт итеп ятам,шулай булгач сине дә шулай ук дип беләмен. Безнең монда шул инде иртән-кичен тизерәк тә-тиззерәк чыда гына. Пока бернинди кыенлыкларым юк, ну ләкин син туганнарымны гына уйлыйм, тамакларым тук, өсләрем бөтен, ашау-эчү турларына элеккечә диярлек, минем өчен кайгырма, исән булсам бер авылга кайтырмын әле, ну ләкин ышанмыйм кайтырыма. Бер җиргә чыгармыйлар. Шәһәрдә йөргәнебез юк, чыгарсалар кышкы киемнәр белән карточкага төшәрмен дип йөргән идем, булмас инде ахры. Аннары менә нәрсә безнең монда 23-февраль көнне ягъни Кызыл Армия көнне Ульяновски шәһәре күләмендә чаңгы ярышы булды, ул чаңгы ярышында мин дә катнаштым, ярыш 20 км га булды, ярышта мин бөтен гарнизон (шәһәр) күләмендә 2-урынны алдым. 2- урынны алганым өчен 150 сум акча белән бүләкләделәр и полковник тарафыннан благодарность алдым. Праздник очень хорошо прошла. Мин сиңа моңылчы син җаныма бернинди дә ях... гына хатларымны җ ибәрә алмадым, (...бу урында ертып алынган – Х.Р.) сиңа язасы сүзем бетте минем. Хәзер үземнең турыма тукталмаска булдым. Авыл күләмендә нинди яңалыклар бар, нигә миңа авыл хәлләрен бер дә миңа язмыйсың, минем бик беләсем килә, кызлар-яшьләр бармы, кемнәр-кем белән йөри, клубта кинолар буламы, вечерлар буламы, гармуннар белән чобалучылар бармы. Аннары, Әминәләргә мин хат язган идем, алар җавап язмадылар, Гөлчирәгә, аннары Ясәви абзыйларга хат язган идем, берсеннән дә хатлар алмадым әле. Армия сафларындагы иптәшләремнең хатлары киләме, Мулланың, Нуриның, Гәрәйнең, Шәрифнең, общем кемнәрнең килми, кемнәрнең килә, барсына да җ авап яз, сеңлем Мәдинә. Әминә, Сания, Гыйлмиса, Мәүлиха, Фәйрүзә(өчтин), Хаҗи Фәйрүзәсе, Минисалар кемнәр белән йөри, нинди генә хәл булмасын, нәрсә генә беләсең барсын да аңлатуыңны үтенәмен. Актүшнең, Сәләхинең хаты киләме, Самаркандтагы һәм Сәләхидәге әйберләрем килдеме. Кирами абыйларның адресын җибәр әле. Мин аларның адресларын оныттым. Җибәрми калма (мохан). Кизелдә эшләүче авылдашларның хатлары киләме, ничек дип килә, гомумән читтәге кешеләрнең

хатлары ничек дип килә, барчасына да җавап җибәрми калма. Зайнагетдин абый нинди эштә, һаман да Бондюг заводындамы, Сәләхетдин абыйның  хаты килмиме? Аннары менә нәрсә тормыш хәлләрегезне әйтеп яз, Бондюг заводында оннар-майлар, итләр кыйммәтме, колхоз икмәк өләштеме, авылда иске укытучыларны һам...(ертылган – Х.Р.)...бармы авылда, фронттан кемнәр кунакка кайтты, “кунакка  кайттылар”дип язгансың хатка, нинди сәбәпле алар (ертылган) икән белмим, ә безнең турда уйламагыз да кунакка кайтарырлар дип, кайтулар бетте инде ул. Минем өчен уйланмагыз ул кадәре, бер әйләнеп кайтырмын әле үлмәсәк. Аннары менә нәрсә, Галләмов Хаҗи һаман да Кизелдәме, әллә булмаса авылга кайтмадымы. Хатлары килмиме, шулай ук Миннәхмәтләре кайда икәннәре билгелеме? Мин әйберләрем турында янам, булмады шул вакытлар җибәрергә бөтен эшләгәннәрем китте шул әрәмгә,  бөтен эшләп йөргәннәрем “чукынды” ахры  25 м Сәләхидә генә иде, ояты беткән икән, ни өмете белән ул әйберләрен калдырмады дип әйтте  икән. Җибәрмәм, ничек тә булса кайтарырмын әле. Әминәгә, ...ларга (аңлашылмый -  Х.Р.) барча дусларыма әйт, хат язсыннар, алу белән хат яз, сеңлем  Мәдинә. Анары әйтим әле, дусларың белән  карточкаңны     (хат шунда тәмам – Х.Р.)

Адрес:  Куйбышевская область

Г, Ульяновск      пІя  120І9

Передать  Калимуллину Галию М.

Шушының буенча хат яз Мәдинә

Озаклама җаным өзелеп хат көтеп калучы абыең Гали.

Язучы     .....(имза)

Кызлар  кулларыгызны кысып калам.

(имза)

25.2.42

(имза)

Воинское

Г.Казань  Бондюжский   р-н   деревне Бизяки Передать: Калимуллиной Мадине

Получить:  Калимуллин Г.М.

Письмо на почту поступило 2.3.42

**Бу хатлар латин алфавиты кулланып язылганнар. Җавап хатларын да латин хәрефләре белән язганнар.**

Бу шәхси адресланган хатларны теләсә кем укырлык итеп интернетка куюның максаты -  сугыш фаҗигасенең нинди ачы кайгылар китергәнен шушы ике хат мисалында булса да бүгенге заман яшүсмерләренә күрсәтү.  Хатның авторы 19...22 яшьлек гомере  эчендә никадәр кыенлыклар

кичергәнен дә сөйләп бетерми, өмет һәм өметсезлек, яшьлек дәрте һәм алдагы көннәрдә үлемгә каршы барачагын уйлап әле хәл сораша, әле ачыктан-ачык хушлаша.  Егетләр һәм кызларга да, ата-аналарга да, дус-ишләргә дә гыйбрәт алырлык нәрсәләр язылган бит.

Галиәхмәт Бәзәкә авылында зур гаиләле крестьян хуҗалыкларының берсе булган Кәлимуллин Мифтахетдиннең  5-нче баласы. 1920 елда, әтисе Беренче Бөтендөнъя сугышында катнашып, алты ел әсирлектә булып авылга әйләнеп кайткач, үзе юкта хәләл җефете Фәрхеҗиһан үлеп китеп аның сеңелесе Шәмсеҗиһанга никахлангач, әнисенең беренче баласы булып туа. Аңардан соңгы балалары: Мәдинә (1923), Әминә (1927), Нуриәхмәт (1930), Мөхәмәтнур(1933), Сәетнур (1936), Диләфрүз (1939). Аталары Мифтахетдин (1881-1945, 5 агай-эне, 4 кыз туган).

Аларның атасы Кәлимулла (4  агай-эне, 4 кыз туган)

Аларның атасы Нигъмәтулла (5 ир туган)

Аларның атасы Салих(Салим ?). Бу нәсел -   бик күп ир-атлы игенчеләр нәселе, бөртеклеләрдән арыш, бодай, борай, солы, арпа, борчак игү өстенә җитен белән киндер дә устереп эшкәрткәннәр. Имана җирләре дә, атлары да күп булган. Туку станокларын, атлар өчен дирбия , арба-чаналарны агай-эне үзе эзерләгән (балта эшенә Гыйләчтин дигәне остарак булган). Өстәмә табыш өчен Мифтахетдин берүзе өчәр олау белән Казан яки аннан да ары товарга йөргән. Баржадан химзаводка ат белән чимал ташыган, үсмер малай Галиәхмәт  абыйлары  Сәләхетдин, Зәйнагытдин белән бергәләп талчыбыктан тара өчен зур кәрзиннәр  үргәннәр. Ә хатын-кызлар киндер-җитеннән җеп эрләп ярдәм иткән. Өсләре бөтен, тамаклары тук яшәгән.  Ачлыктан интегүче күршеләренә гаиләдә ни ашасалар, шуннан өлеш чыгарырга тырышкан Мифтахетдин абзый. (Гомәр Габдулласының апасы Шәмсекамал әби гомере буена алар гаиләсен рәхмәт әйтеп телгә ала иде). Гаилә архивында алар кулының җылысын безнең буынга кадәр китереп тоташтырган чаршау, ашъяулыклар, сөлгеләр, идән җәймәләре  саклана, берничә үргән кәрзин дә бар. Галиәхмәт  әле кумак тиреләре, юкә каерылары  да әзерләштергән.

Галиәхмәт   мәктәпне авылда тәмамлый, аннан соң Алабугада библиотека техникумында укый. 3 еллап Бондюгта район судъясы Вафин янында секретарь булып эшли. 1939 елда вербовщикка языльп Кизел шахтасына китә. Армиягә дә шуннан алынып, сугышка да шуннан киткән. 2005 елның 22 июнендә әнием Мәдинә белән сугыш чоры истәлекләрен яңартып утырганда шулай дигән иде: “Галиәхмәт абайның сугышка киткәнен  чәтер Фәтхыяттәй кайтып сөйләде. Гармуны белән моңлы итеп җырлап поездга утырып киткән. Китәр алдыннан авылга дип бик күп әйбер (аяк киемнәре, ситсылар 40 метр) туплаган булган. 2 посылкалык әйберен бергә эшкә килгән авылдаш егетләргә ышанып куеп китте. Миңа ышанмагандыр инде, үземә калдырган булса, салган булыр идем”,-дигән. Ул әйберләре тәки килмәгән. Кызганыч, күпсанлы гаилә өчен дип тир түгеп хәләл көч белән җыйган малы да,  әти-әнисенең газиз баласы үзе дә  билгесез  югалган. 1990-нчы елларда Подольск һәм Гатчина архивларына язып эзләтеп караган идек тә, архивларны ачып салмыйлар иде шул, бернинди ачыклык та кертмәде ул язышулар. Йөзгә кадәр диярлек яшәгән әнисе аны гел исәндерсыман итеп көтте. Туган иле азатлыгы өчен пешкән җиләктәй яшь гомерен биргән Галиәхмәт абзыем, гәрчә миңа аны күрү насыйп булмаса да, намуслы, батыр йөрәкле, уйлары һәм гамәлләре белән дә матур кеше буларак күзалдымда яши. Геройлар рәтендә гәүдәләнә. Алланың рәхмәтендә булсын, хакыйкатьне белүче  бары Ул гына.

Мәдинә сеңлесенә исә сугыш башланганда әле 18 е дә тулмаган була. “Шул елны кыш башлангач, мине һәм Нәбкә Хәлимәсен Таҗимулла абзый ат белән Алабугага  бригадирлар курсына илтеп куйды. Бер марҗада 1 ай фатирда торып укып кайттык. Кайтуын үзебез җәяү кайттык. Шуннан

1942 елдан сугыш беткәнче бригадир булып эшләдек. 11 бригада иде. ...минем бригаданың 2 аты сазлыкка батып үлде.  Ачлыктан хәлләре булмагандыр инде. Башаров Госман абзый белән Гыймазетдинов Гыйлфан абай судта мине яклап төрмәдән йолып калдылар, “ул 18 яшьлек кызны төрмәгә утыртып кына колхоз баемас”диделәр. Урыннары җәннәттә булсын. Әтәй үлде. Атлары колхозда иде, аның аты әйбәт ат исәпләнә иде. Нуриәхмәт энем урынына шул ат белән урман эшенә үзем киттем. 1 атна эшләгәч, ул ат өяләде. Тартма Гайнетдин абзый: “Эшкә чыкма, атыҢ өяләгән, атың рәтләнгәнче атыңны кара,”-дип, эшләтмәде, әмма хезмәт көне язып барды. Урыны җәннәттә булсын.” –дип сөйләгәнен язып алган идем. Фидакарь әниемә һәм калган бригадир апаларга Алланың рәхмәте насыйп булсын. (Альт а апаның авылыбыз тарихына багышланган китабындагы бер фотосүрәттә әнә шул бригадир хатын-кызлар арасында арткы рәттә сулдан беренчесе -гәрәбә муенса кигәне- әнием Мәдинә булыр).

Мәдинә кызы Рәмзия . 6 май 2017 ел.



Мәдинә Кәшбиева



Калимуллин Галиахмет



Калимуллин Галиахмет на фронте



1946 г Маньчжурия (Калимуллин Галиахмет)



Отец Калимуллина Галиахмета